**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА НОВОТУМБИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЯНА ТУМБА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Тумба ав. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Яңа Тумба авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 10 апрелендә Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлегенең Яңа Тумба авылында Яңа Тумба авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Яңа Тумба авылы, Шоссе урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында 16 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Яңа Тумба авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Тумба торак пунктында ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

«Әйе» «Юк»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Осипов